ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2021 г.Лениногорск № 37

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәр Советының 2018 елның 16 февралендәге 140 номерлы карары белән расланган Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә Иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494 номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск шәһәр прокурорының «Торак» илкүләм проектын тормышка ашыруны регламентлаучы закон таләпләрен тиешенчә үтәмәү турындагы 2021 елның 16 апрелендәге 02-08-02 номерлы күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәр Советының 2018 елның 16 февралендәге 140 номерлы карары белән расланган Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә Иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары,» сүзләреннән соң 2 абзацны «комплекслы үсешкә тиешле территорияне планлаштыру буенча документлар проекты буенча, » сүзләре белән тулыландырырга;

«территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары,» сүзләреннән соң 1 пунктны «комплекслы үсешкә тиешле территорияне планлаштыру буенча документлар проекты буенча,» сүзләре белән тулыландырырга;

3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.1. Территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны тормышка ашыру өчен җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү таләп ителгән очракта, җирле администрация башлыгы карары нигезендә, җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча һәм комплекслы үсеш алырга тиешле территорияне планлаштыру документлары проекты буенча бер тапкыр ачык тыңлаулар һәм (яки) иҗтимагый фикер алышулар үткәрү рөхсәт ителә.»;

5 пунктны «территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары,» сүзләреннән соң «комплекслы үсешкә тиешле территорияне планлаштыру буенча документлар проекты буенча,» сүзләре белән тулыландырырга;

6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү әзерләнгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны кабул итүгә бәйле рәвештә иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар территорияне үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.».

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында, рәсми публикаторда һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск муниципаль районы Башлыгы урынбасары Г.М. Рафиковага йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры — Р.Г. Хөсәенов